РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 15 октябре № 12

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә, җир салымы ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләп, җир салымын билгеләргә:

1.1. сәнәгать җирләренә һәм башка махсус билгеләнештәге җирләргә караган 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләүгә бирелә торган кишәрлекләргә карата 0,05 процент;

1.2. физик һәм юридик затлар тарафыннан анда торак төзелешен гамәлгә ашыру шартларында милеккә сатып алынган (бирелгән), физик затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган шәхси торак төзелешеннән тыш, җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент;

1.3. аттракционнар белән җир кишәрлекләренә карата 0,13 процент;

1.4. автомәктәпләр полигоннары һәм автодромнары белән җир кишәрлекләренә карата 0,2 процент;

1.5. шәһәр электр транспорты корылмалары һәм коммуникацияләре белән җир кишәрлекләренә карата 0,22 процент (трамвай һәм троллейбус парклары, депо, җитештерү һәм ремонт остаханәләре һәм шәһәр электр транспорты эше өчен һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган башка объектлар);

1.6. җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент:

1.6.1. җирлекләрдә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы кулланылышы зонасы составындагы җирләргә кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган;

1.6.2. торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокукындагы өлештән тыш);

1.6.3. эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шәхси торак төзелеше, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләрен, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләрен;

1.6.4. Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән;

1.6.5. гаражлар, базлар өчен сатып алынган (бирелгән);

1.7. физкультура-спорт учреждениеләре биналары, каралтылары һәм корылмалары (шул исәптән спорт мәктәпләре) урнашкан җир кишәрлекләренә карата 0,7 процент;

1.8. автостоянкалар биләгән җир кишәрлекләренә карата 1 процент;

1.9. башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 процент.

2. Рөхсәт ителгән файдалануның бер төреннән артык булган җир кишәрлегенә карата әлеге кишәрлек өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре буенча җир салымы ставкасының иң зур күләмен кулланырга кирәклеген билгеләргә.

3. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.

4. Салым ташламаларын бирергә:

4.1. шәхси ярдәмче хуҗалык һәм шәхси торак төзелеше өчен бирелгән һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә (өлешләренә) карата җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә, түбәндәге салым түләүчеләр-физик затлар категорияләренә:

4.1.1. Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына, Дан орденының тулы кавалерларына;

4.1.2. Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм инвалидларына, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидларына;

4.1.3. I һәм II төркем инвалидларга;

4.1.4. балачактан инвалидларга, инвалид балаларга;

4.1.5. «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Маяк» җитештерү берләшмәсендә 1957 елдагы авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны агызу аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган физик затларга;

4.1.6. аерым куркыныч бүлекчәләре составында атом-төш һәм термоядерлы корал сынауларында, кораллану чараларында һәм хәрби объектларда атом-төш җайланмалары һәлакәтләрен бетерүдә турыдан-туры катнашкан физик затларга;

4.1.7. атом-төш җайланмаларының теләсә нинди төрләре белән бәйле, шул исәптән атом-төш коралы һәм космик техниканы да кертеп, сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр нәтиҗәсендә нур авыруын алган яки кичергән яки инвалид булып калган физик затларга;

4.2. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

4.2.1. оешмаларага – гражданнар каберлекләре биләгән җир кишәрлекләренә карата;

4.2.2. өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга, 2011 елның 18 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт яны җир кишәрлеге), бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен түләүсез милеккә бирелгән җирләрдән файдаланган өчен;

4.2.3. әлеге карарның 4.2.2 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар балаларына, 2011 елның 18 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт яны җир кишәрлеге), бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен түләүсез милеккә бирелгән җирләрдән файдаланган өчен;

4.2.4. индустриаль (сәнәгать) паркларына һәм сәнәгать технопаркларына;

4.2.5. «Түбән Кама» алгарышлы социаль-икътисади үсеш территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешү кысаларында резидентлар реестрына тиешле язма кертелгән көннән алып, 10 елга кадәр срокка инвестицион проектны тормышка ашыру өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата резидент-оешмаларга.

5. Әлеге карар белән билгеләнгән салым ташламалары, карарның 4.2.4, 4.2.5 пунктларында каралган очраклардан тыш, арендага (файдалануга) бирелә торган җир кишәрлекләренә (өлешләргә) кагылмый дип билгеләргә.

6. Түбән Кама шәһәр Советының 2019 елның 7 ноябрендәге 39 номерлы «Җир салымы турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин